ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 28 гыйнвары** **Чистай шәһәре** **№ 54**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты карарларының
үз көчен югалтуын тану турында

Чистай шәһәр прокуратурасының муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру функцияләрен үтәүнең административ регламентына 2022 елның 25 гыйнварындагы 02-08-02-2022 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 декабрендәге 1055 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшерү буенча административ регламентын;
- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшерүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 декабрендәге 1055 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 8 февралендәге 58 номерлы карарын;
- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшерүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 декабрендәге 1055 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 23 гыйнварындагы 26 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында

(http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов